# Туйда

Рәфикъ Юнысов сүзләре






1972

Беренче туй күптән онтылды,
Көмеш туйга әле иртәрәк.
Тик йөрәгем ярсып тибеп куйды
Туй буласы йортка җитәрәк.

Кушымта:
Туйда, туйда, туйда җырлап һич туймыйсың, эх!
Кияү булып йөргән чакны уйлыйсың.
Бас, бас, бас бу якта,
Бас, бас кызу чакта.
Тал булып бөгелсен такта —
Туйда бии тукмак та.

Әйтерсең лә урам әйләнеп
Төштек менә икәү чанадан.
Кар-бураннар, кыңгыраулар белән
Яшьлек кайтты кебек яңадан.

Кушымта.

Еллар үткәч, яшәү шатлыгы
Көчле була икән бигрәк тә.
Туйда биеп идән җимерерлек
Дәрт саклана икән йөрәктә!

Кушымта.